РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ КАЗКЕЕВСКОГО СЕЛЬСКО-
ГО ПОСЕЛЕНИЯ
АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬ-
НОГО РАЙОНА

423761, село Казкеево,
ул. Первомайская,дом 2а,
Тел. 3-44-46

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ КӘЗКӘЙ АВЫЛ
ЖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

423761, Кәзкәй авылы,
Беренче май., 2а нчы йорт.
Тел.3-44-46

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

03 апреля 2024 года № _2__

Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Кәзкәй авыл җирлеге Советының «Җир салымы турында» 14.12.2023 ел 24 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Салым Кодексының 31 бүлегенә ярашлы рәвештә Татарста Республикасы Актаныш муниципаль районы Кәзкәй авыл җирлеге Советы карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Кәзкәй авыл җирлег Советы «Җир салымы турында» 14.12.2023 ел 24 номерлы карарына түбәндәг үзгәрешләр кертергә:

1.1. 2 нче пунктта:

- беренче абзацта "җир кишәрлекләренең кадастр бәясеннән" дигән сүзләрн төшереп калдырырга;

- өченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

- «0,3% күләмендә торак фонды һәм (яисә) торак-коммуналь комплексыны инженерлык инфраструктурасы объектлары белән биләнгән җир кишәрлекләренә (тора фондына һәм (яисә) торак-коммуналь комплексының инженерлык инфраструкурас объектларына карамаган күчемсез милек объектына туры килә торган җир кишәрлегене бер өлешеннән тыш) яисә торак төзелеше өчен сатып алынган (бирелгән) җи кишәрлекләренә карата шәхси торак төзелеше өчен сатып алынган (бирелгән эшкуарлык эшчәнлегендә кулланыла торган җир кишәрлекләренә карата ;

1.2. 3 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Салым түләүчеләрнең түбәндәге категорияләрен җир салымы түләүдән аза итәргә:

- I төркем инвалидлыклары булган инвалидлар һәм балачактан инвалидлар;

- Бөек Ватан сугышында катнашучылар, ветераннар һәм инвалидлар, шулай у хәрби хәрәкәтләр ветераннары һәм инвалидлары;

- шәхси торак йортларда яшәүче Бөек Ватан сугышында һәлак булга катнашучыларның тол хатыннары;

хезмәт бурычларын үтәгәндә һәлак булган хәрбиләрнең һәм дәүлә хезмәткәрләренең әти-әниләре һәм хатыннары;

- «Чернобыль АЭСындагы һәлакәт нәтиҗәсендә радиация йогынтысына дуча булган гражданнарны социаль яклау турында» Россия Федерациясенең 1991 елның 1

маендагы 1244-1 номерлы Законына, «1957 елда «Маяк» җитештерү берләшмәсенд һәм Теча елгасына радиоактив калдыклар җыюда радиация йогынтысына дучар булга Россия Федерациясенең социаль ярдәм алу хокукына ия затлар» 1998 елның 2 ноябрендәге 175-ФЗ номерлы Федераль законына һәм «Семипалатинск полигонында атом сынаулары нәтиҗәсендә радиация йогынтысына дучар булган гражданнарг социаль гарантияләр турында» 2002 елның 10 гыйнварындагы 2-ФЗ номерлы Федерал законына ярашлы физик затлар;

- Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясендә өлешч мобилизация игълан итү турында» 2022 елның 21 сентябрендәге 647 номерлы Указ нигезендә Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәтк чакырылган Актаныш муниципаль районы Кәзкәй авыл җирлеге территориясендә яшә урыны буенча даими теркәлүгә ия булган Россия Федерациясе гражданнары һә аларның гаилә әгъзалары (күрсәтелгән гражданнар, балигъ булмаган балалар һәм 2 яшькә кадәрге балалар, белем бирү оешмаларында көндезге уку формасы буенча беле алучылар, ата-аналар, эшкә сәләтсез тәрбияләнүчеләр);

- Актаныш муниципаль районы Кәзкәй авыл җирлеге территориясендә яшәү урын буенча даими теркәлүгә ия булган, хәрби хезмәт үтү турында контракт төзегән яки Росси Федерациясе Кораллы көчләренә йөкләнгән һәм махсус хәрби операциядә катнашка бурычларны үтәүдә ирекле ярдәм турында контракт төзегән Россия Федерацияс гражданнары һәм аларның гаилә әгъзалары (күрсәтелгән гражданнар белән никахт торучы (тормыш иптәше), балигъ булмаган балалар һәм 23 яшькә кадәрге белем бир оешмаларында көндезге уку формасы буенча укучы балалар, ата-аналар, эшкә сәләтсе тәрбияләнүчеләр) ;

Актаныш муниципаль районы Кәзкәй авыл җирлеге территориясендә яшәү урын буенча даими теркәлгән Россия Федерациясе гражданнары Донецк Халык Республикасы Луганск Халык Республикасы, Запорожье өлкәсе, Херсон өлкәсе һәм Украин территорияләрендә махсус хәрби операциядә катнашучылар (катнашучылар) яки ан үткәрү белән бәйле бурычларны турыдан-туры үтәүчеләр (башкаручылар), шул исәпт һәлак булганнар, хәбәрсез югалганнар һәм аларның гаилә әгъзалары (күрсәтелгә гражданнар белән никахта торучы) балигъ булмаган балалар һәм 23 яшькә кадәрг белем бирү оешмаларында көндезге уку формасы буенча укучы балалар, ата-анала эшкә сәләтсез тәрбияләнүчеләр).»;

1.3. 4 нче пунктта:

- «дачалар белән» сүзен чыгарырга;

- «законнарда билгеләнгән тәртиптә даими теркәлү (прописка) " сүзләрен «тормы урыны буенча даими теркәлү»сүзләре белән алыштырырга;

1.4. 5 нче пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Салым түләүче оешмалар өчен хисап чоры булып календарь елның беренч кварталы, икенче кварталы һәм өченче кварталы танылa.

Салым түләүче оешмалар агымдагы салым чорының беренче, икенче һәм өченч кварталлары тәмамланганнан соң җир участогы кадастр бәясенең процент өлеше буенч тиешле салым ставкасының дүрттән бер өлеше күләмендә аванс түләүләре белән җи салымын түлиләр.

Җир салымы салым түләүче оешмалар тарафыннан салым чоры тәмамланганна соң 28 февральдән дә соңга калмыйча түләнергә тиеш. Җир салымы буенча аван түләүләр салым түләүче-оешмалар тарафыннан хисап чоры тәмамланганнан соң айны 28 нче көненнән дә соңга калмыйча түләнергә тиеш.»;

1.5. 6 нчы пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6. Җир салымы һәм җир салымы буенча аванс түләүләре салым түләүчелә тарафыннан Россия Федерациясе Салым кодексының 389 статьясына ярашлы рәвешт салым салу объекты дип танылган җир участоклары урнашкан урын буенча бюджет түләнә.

Салым ташламаларына хокуклы салым түләүчеләр, шул исәптән салымнар һәм җыемнар турындагы законнарда билгеләнгән салым ташламасы рәвешендә, салым органына үз сайлавы буенча салым ташламасы бирү турында гариза тапшыралар, шулай ук салым түләүченең салым ташламасына хокукын раслаучы документлар тапшырырга хокуклы.».

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга (PRAVO.TATARSTAN.RU).

4. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыккан көннән үз көченә керә һәм 2024 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

Рәислек итүче Н.К Хөҗҗәтов